МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

28.12.2016

Казан ш.

№ 07-158

Хисап финанс елында файдаланылмый калган, максатчан билгеләнешкә ия булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗның булуы турында Татарстан Республикасы бюджет керемнәре баш администраторларының карарларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242 статьясы һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексының 97 статьясы нигезендә, б о е р ы к б и р ә м:

1. Хисап финанс елында файдаланылмый калган, максатчан билгеләнешкә ия булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗның булуы турында Татарстан Республикасы бюджет керемнәре баш администраторларының карарларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерү тәртибен (кушымта итеп бирелә) расларга.

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары О.А.Кисаповага йөкләргә.

Министр Р.Р.Гайзатуллин

Татарстан Республикасы
Финанс
министрлыгының
28.12.2016 ел,№ 07-158
карарына кушымта

Хисап финанс елында файдаланылмый калган, максатчан билгеләнешкә ия булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗның булуы турында Татарстан Республикасы бюджет керемнәре баш администраторларының карарларын Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештерү тәртибе

1. Бу Тәртип хисап финанс елында файдаланылмый калган, максатчан билгеләнешкә ия булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗның булуы турында Татарстан Республикасы бюджет керемнәре баш администраторларының карарларын (алга таба – Карар, бюджетара трансфертлар) Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (алга таба – Министрлык) белән килештерү кагыйдәләрен билгели.

2. Керемнәрнең баш администраторлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән срокларда, түбәндәге документлар белән, Карарны Министрлыкка килештерүгә тапшыра:

а) бюджетара трансфертлар калдыкларының килеп чыгу сәбәпләреннән торган аңлатма язуы;

б) бюджетара трансфертларга ихтыяҗның булуы турында җирле үзидарә органының ирекле рәвештә язылган мөрәҗәгате күчермәсе, агымдагы финанс елында тиешле максатларга бюджетара трансфертлардан файдалануга ихтыяҗның нигезләнеше белән;

в) Бу Тәртипкә кушымта нигезендәге формада бюджетара трансфертларга ихтыяҗның булуы турында мәгълүмат.

3. Министрлык, тапшырылганнан соң унбиш көн эчендә, Карарны һәм бу Тәртипнең 2 пункты нигезендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм Карарны килештерү яки килештерүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4. Министрлык түбәндәге очракларда Карарны килештерүдән баш тарту турында карар кабул итә:

а) тапшырылган документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүматлар чагылдырылганда яки бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән документлар арасыннан кайберләре тапшырылмаганда;

б) Карарлар Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән срокларны санга сукмыйча тапшырылганда;

в) бюджетара трансфертларга ихтыяҗны раслауга игълан ителгән сумма хисап финанс елында үтәлмичә калган бюджет йөкләмәләре суммасыннан артканда;

г) бюджетара трансфертларга ихтыяҗны раслауга игълан ителгән сумма җирле үзидарә органнары тарафыннан керемнәрнең баш администраторларының лицевой счетларына күчерелгән средстволар калдыклары суммасыннан артканда;

е) агымдагы финанс елында Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетка файдаланылмый калган бюджетара трансфертларны тапшыруның элек билгеләнгән максатларына туры килүче максатка бюджетара трансфертлар бирү күздә тотылганда.

5. Министрлыкның Карарны килештерү яки килештерүдән баш тарту турында карары керемнәрнең баш администраторына хат белән, тиешле карар кабул ителгәннән соң ике эш көне эчендә, җиткерелә.

Хисап финанс елында файдаланылмый калган, максатчан билгеләнешкә
ия булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара
трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗның
булуы турында Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш
администраторлары карарларын Татарстан Республикасы Финанс
министрлыгы белән килештерү тәртибенә кушымта

Хисап финанс елында файдаланылмый калган, максатчан билгеләнешкә ия булган субсидияләр, субвенцияләр һәм башка бюджетара трансфертлар рәвешендә алынган бюджетара трансфертларга ихтыяҗның булуы турында мәгълүматлар

________________________________________________________

(Татарстан Республикасы керемнәренең баш администраторы атамасы )

| N п/п | Муниципаль берәмлек атамасы | Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына бюджетара трансферт калдыгы, сумнарда* | Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау КБК ( баш бүлүченең, максатчан статья бүлегенең, бүлекчәсенең коды) | Татарстан Республикасы бюджетыннан бюджетара трансферт бирелү елы (беренче тапкыр) | Татарстан Республикасы дәүләт программасы атамасы (булган очракта) | Бюджетара трансферт хисабына тормышка ашырыла торган чара/объект (дәүләт программасы кысаларында) атамасы | Татарстан Республикасы бюджетына бюджетара трансфертларны кире кайтаруга түләү поручениесе номеры, датасы | Бюджетара трансфертларны Ттатарстан Республикасы бюджетына кире кайтаруга түләү поручениесе буенча сумма, сумнарда * | Татарстан Республикасы бюджетының баш администраторы тарафыннан расланган, агымдагы финанс елының 1 гыйнварына бюджетара трансферт калдыгына ихтыяҗ, сумнарда* |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 |
| 1 | | | | | | | | | |
| 2 | | | | | | | | | |
| 3 | | | | | | | | | |
| 4 | | | | | | | | | |
| ... | | | | | | | | | |
| ... | | | | | | | | | |
| 5 | Всего | | | | | | | | |

* Сумма, өтердән соң, тиеннәренә кадәр күрсәтелә
администраторы җитәкчесе

________________ ________________________

имза Ф.И.О.

Баш администраторның баш бухгалтеры

________________ ________________________

имза Ф.И.О.

Башкаручы ________________ ________________________